Ислам нуры
اسلام نورى
«Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар»
(Коръән Кәрим. 2-256)
12+
№ 18 (694) 26 сентябрь 2019 ел (1440, Мөхәррәм) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

# Дөнья сәфәре



Дөньяда яшәүче кешеләр дә сәфәр хәлендәдер. Адәмнәр вә хайваннар һәрберсе бер якка карап сәфәр чыгалар вә һичтуктаусыз йөреп торалар. Кирәк — ашап-эчеп утырсыннар, кирәк — уяу вә йокыда булсыннар, алар һаман сәфәрдәдер. Баралар. Барган саен, алларында бик ерак күренгән нәрсәләр сәгать саен якыная торырлар. Яңа гына артта калган әйберләр бик ерак киткән буладыр. Үзләренең дөнья сәфәрендә икәнлекләрен белмәгән вә ашыгып киткәнлекләрен сизмәгән кешеләр тирә-якларына карасыннар. Шул вакытта туктаусыз йөреп торуларын белерләр. Яшьләр картайганнар, картлар дөньядан киткәннәр. Юклар дөньяга килгәннәр, дөньяга килгәннәр үсеп мәктәпләргә йөри башлаганнар. Балалар дөньяга килүләрен дә белми, һичбер эшкә көчләре житми. Соңрак утырырга өйрәнәләр, көлә вә ашыйлар, уйныйлар вә аякларында йөриләр. Теш чыга, мәктәпкә баралар. Укырга-язарга өйрәнәләр. Үсәләр, өйләнәләр, ата вә ана, соңрак әби вә бабай булалар. Чәчләре агара, тешләре төшә, билләре бөкрәя вә көчләре бетә. Чөнки бу нәрсәләр — дөнья сәфәренең хикмәтләредер, вокзаллары, тукталышларыдыр.

**(Риза ФӘХРЕДДИН. “Балалар өчен”.Фото интернеттан алынды)**

# Чаллы яңалыклары



“Сөембикә” мәчетендә Чаллы мөхтәсибәте имамнарының чираттагы җыелышы булды. Мәҗлес барышында “Җәмигъ” мәчете төзелеше, мәчетләрдә никах уку, мөселман балаларының мәктәпләрдә булган проблемалары белән бәйле темаларга фикер алышынды. Имам-мөхтәсиб Әлфәс хәзрәт Гайфуллин имамнарны мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның яңа боерыгы белән таныштырып китте. Җыелыш ахырында имамнар тарафыннан ашыгыч никахлар укытмаска, талак сорауларын казыятка тапшырырга һәм никахларны бары тик имамнар яки аларның ярдәмчеләренә генә укырга рөхсәт бирергә дигән фикергә килделәр. Өйлә намазыннан соң мәчеттә Корбан ашы мәҗлесе дә үткәрелде.

***

“Утыз-Имәни” мәчетендә бу елны “ДУМ РТ Хаж” агентлыгы аркылы олы хаҗда булып кайткан хаҗилар мәҗлесе булып үтте. Әлеге чарага агентлыкның җитәкчесе Ранис хәзрәт Вахитов та килгән иде. Чаллы шәһәре хаҗилары җитәкчесе булып барган Инсаф хәзрәт Сәүбанов хаҗиларны тәбрикләү сүзләре белән мәҗлесне башлап җибәрде. Соңрак шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин, Ранис хәзрәт Вахитов һәм “Утыз-Имәни” мәчете имам-хатыйбы Салихҗан хәзрәт Гайниев хаҗиларны шушы дини йоланы үтәүләре белән котладылар һәм хаҗ агентлыгы эшчәнлеге белән таныштырып үттеләр.

***



“Рамазан” мәчетендә Гашура көненә багышлап ифтар мәҗлесе үткәрелде. Анда утызга якын кеше катнашты. Мәҗлес барышында Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин Гашура көне һәм бу көнне ураза тоту фазыйләтләре турында сөйләде. Соңрак мәчет имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Галиуллин “Рамазан” мәчетендә кизүдә утыручы Вәлиев Илдус бабайны 80 яше тулуы белән котлады.

***



Татарстанда күп ел рәттән сентябрь аенда “Экстремизмга - юк!” дигән акция үткәрелә. Чаллы шәһәре мөхтәсибәте дә әлеге айлыкта актив катнаша. 10 сентябрь көнне “Ихлас” мәчете вәкилләре «ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының СПИД һәм йогышлы авыруларны профилактикалау һәм аларга каршы көрәш буенча республика үзәге»нең эшче персоналы белән очрашуда катнаштылар. “Ихлас” мәчете вәкилләре чарага җыелучыларга үгет-нәсихәт бирделәр, төрле юнәлештәге деструктив төркемнәр эшчәнлегенә җәлеп итүнең типик сәбәпләре турында сөйләделәр, кризис шартларында ярдәм итәргә әзер булган ведомство вәкилләре белән таныштырдылар.

“Ак мәчет” мәдрәсәсендә «Экстремизмга – юк!» дигән темага ачык дәрес булып узды. Аны мәдрәсә укытучысы Мөхәммәт хәзрәт Мөхәммәтов алып барды. Дәрес барышында шәкертләргә экстремизм һәм аның чагылышлары турында сөйләнде. Экстремизм кебек күренешкә дини белемсез каршы тору авыр, шуңа күрә Мөхәммәт хәзрәт дини белем алуның мөһимлеген аерым билгеләп үтте. Әлеге ачык дәрестә шәкертләр, укытучылар, шулай ук Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге җитәкчесе Галиуллин Рөстәм Рафик улы да катнашты.

Шәһәребез мәчетләрендә экстремизм һәм терроризм темасына бәйле Җомга вәгазе укылды. “Утыз-Имәни” мәчете имамы Инсаф хәзрәт Сәүбанов “Экстремизмга - юк!” программасы кысаларында “Шәһәр йогышлы авырулар хастаханәсе” персоналы алдында чыгыш ясады.

Мөселман яшьләре өчен велойөгереш, балалар өчен “Ислам - тынычлык һәм мәрхәмәтлек дине” темасына рәсем ясау конкурсы да шушы чаралар кысасында уздырыла.

**Нияз ГАЗИЗОВ.**

## ТР МДН хәбәр итә



Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның мөселман яшьләре белән еллык очрашуы булды. Анда Нәзарәтнең төрле социаль башлангычларын тормышка ашыручы, волонтерлар, мәдрәсә шәкертләре, ислам юлында һәм дөньяви өлкәләрдә өметле яшь белгечләр катнашты. «Изге Коръәнне белү – иң бөек гыйлем, – дип билгеләп үтте Камил хәзрәт. – Аллаһ Илчесенең сүзләрен исегезгә төшерегез: «Арагыздан иң хәерлегез — Коръәнне өйрәнүче һәм аны башкаларга да өйрәтүчедер». Остазның әһәмияте зур. Киләчәктә башкаларны өйрәтү өчен дә укыйбыз бит. Ә Коръәндә Галәмебезнең бөтен серләре тасвирланган. Проблема шунда ки, кайвакыт, без әлеге Бөек Китаптан хикмәт “тартып” чыгару өчен җитәрлек дәрәҗәдә акылга ия түгел».

***

Татарстанда гошер сәдакасын җыеп, аны мохтаҗларга тарату буенча традицион кампания бара. Шул нисбәттән 2019 елның 28 сентябре ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан республикада Гошер көне итеп игълан ителә. Кампания кысаларында бакча уңышының бер өлешен мохтаҗлар файдасына районнардагы һәм шәһәрләрдәге үзәк мәчетләргә тапшырырга мөмкин. Мөселманнардан җиләк-җимеш һәм яшелчәләр кабул ителә. Соңыннан җыелган сәдакалар мохтаҗларга тапшырыла. Беренчеләрдән булып быел гошерне Балык Бистәсе һәм Бөгелмә мөхтәсибәтләрендә җыйдылар. Шунысын билгеләп узарга кирәк: 2018 елда республика халкының бу социаль акциядә гаять актив катнашуы нәтиҗәсендә барлыгы 600 тонна гошер җыелды һәм мохтаҗларга таратылды. Гошер – сәдаканың махсус төре, мөселман кешесе җыеп алган уңышының уннан берен мохтаҗларга бирә. Гошер сәдакасының мәҗбүрилеге шуның белән нигезләнә: һәрбер уңышның хакыйкый сәбәбе булып Аллаһының рәхмәте тора. Әлеге рәхмәткә ирешү һәм киләчәк уңышка өмет баглау өчен, Аның ихтыярына буйсынып, Каләм шәрифтә әйтелгәнчә, гошер бирелергә тиеш. Революциягә кадәр татар-мөселманнарда гошер сәдакасын җыю гадәти күренеш булган, ә совет чорында гошер бәйрәмнәрен уныш бәйрәмнәре алыштырган. Хәзер әлеге хәйрия җыелмалары республика мөселманнары тормышына кайта башлады.

# Остаз – дөнья вә ахирәт тормышын өйрәтүче

***Гомерләрен балалар укытуга багышлаган кешеләргә, дөньяви гыйлем буенча булса да, дини гыйлем буенча булса да, һәркайсына да Аллаһ Тәгалә озын гомер, саулык-сәламәтлек биреп, дөньяда да, ахирәттә дә Үзенең сәгадәтен Раббыбыз насыйп итсә иде.***

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм бер хәдисендә әйтә: син гыйлем бирүче, кешеләрне гыйлемгә өйрәтүче бул. Йә булмаса, гыйлемне өйрәнүче кеше бул, тыңлаучы, гыйлемне яратучы бул, башкасы булма, һәлак булырсың, - ди. Моннан аңлашылганча, Пәйгамбәребез һәркайсыбызга гыйлемле булып, шул гыйлемне башкаларга да өйрәтүне йөкли. Димәк, бу - авыр хезмәт. Мөселман кешегә гыйлем алу фарыз: бишектән алып ләхеткә кадәр. Белем алмый икән, димәк, Аллаһ Тәгалә каршысындагы бурычын үтәми. Дөньяви гыйлемме, дини гыйлемме - икесен дә тигез күреп, икесен дә мөселман кеше өйрәнергә тиеш. Гомер буе. Дөньяви гыйлем белән дини гыйлем бер-берсенә бәйләнгән, бер-берсен тулыландырып торалар. Аларны аерып карау һич дөрес түгел. Дин әһелләре дә, дөньяви гыйлем бирүчеләр дә моны аңларга тиеш. Чөнки дөньяви гыйлемнәр дә Аллаһ Тәгалә куйган кануннарны өйрәтәләр. Физика, химия, биология, математика яки бүтән фәннәр - алар барысы да Аллаһның Җир йөзенә урнаштырган кагыйдәләрен өйрәтәләр. Кеше нихәтле галимрәк булса, гыйлемне нихәтле күбрәк өйрәнсә, тирәнрәк белсә, ул Аллаһ Тәгаләгә шуның хәтле якынрак була. Чөнки ул Аллаһ Тәгаләнең бу дөньяны нинди камил сурәттә яраткан икәнен аңлый. Анда бөтен нәрсә кануннарга буйсына, тәртипсез хәрәкәтләнүче бер генә нәрсә дә юк. Бөтенесенең эчендә бертөрле нигез ята. Бөтенесенең төзелеше охшаш, бер-берсенә бәйләнгән һәм берсе-берсеннән башка була алмый аның. Укытучы, дөньяви фәнне укытса да, ул Аллаһның барлыгына инанырга тиеш. Аллаһны танырга да шушы гыйлемнәр ярдәм итә. Без менә бик күп укый торган «Әл-Мүлек» сүрәсендә (3 нче аять) Аллаһ Раббыбыз әйтә: «Фәрҗигил-бәсара һәл тәраа миң фүтуур». Минем яралтканымда һичбер кимчелек табылмас, - ди. Укытучылар исә Аллаһның җиргә урнаштырган кануннарын кешеләргә җиткерәләр. Коръәни Кәримдә Аллаһ Раббыбыз әйтә: «Үә мән әхсәнү кауләм-миммән дәгәәәә иләәллааһи үә гәмилә-саалихәү-үә каалә иннәнии минәл-мүслимииин» (41:33). - Минем сүземне адәм балаларына җиткерүчедән дә сөйкемлерәк кеше юк, - диде. Димәк, дөньяви гыйлем бирүче укытучылар - Аллаһның җиргә урнаштырган кануннарын кешеләргә җиткерәләр, ә инде дини гыйлемгә өйрәтүчеләр Аллаһ Тәгаләнең әхлак, тормыш кору, үзен-үзе тоту турындагы сүзләрен ирештерәләр. Димәк, икесе дә дөньяви һәм дини гыйлемнәрне - Аллаһ сүзен кешеләр аңына салалар. Әти-әни, өлкәннәр хакы шикелле үк, укытучылар, мөгаллим-мөгаллимәләрнең дә безнең өстә гаять зур хаклары бар. Чөнки - гади кешеме, олы дәрәҗәлеме - һәркайсыбызның да укытучысы, остазы, остабикәсе бар. Һәм без шушы укытучыларыбызны истә тотарга, хөрмәтләргә, хәлләрен белергә тиеш. Бу - аларның адәмнәр өстендә булган хакы.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм Гомәр разыйал-лаһү гәнһүдән сораган: «Аллаһ Тәгаләдән кала синең тагын кем каршында бурычың бар, кемнең хакы зуррак?» - дип. Шуннан Гомәр (р.г.): "Остазымныкы", - дип җавап биргәч кенә канәгать калган. Чөнки остаз - дөнья вә ахирәт тормышын өйрәтүче.

Бүген безгә дөньяви гыйлемне мәктәптә укытучылар бирә, дини гыйлемне мәдрәсә-мәчетләрдә имамнар, мөгаллим-мөгаллимәләр өйрәтә. Үзләре остаз да, үзләре әти-әни дә булган ата-аналар да бар, әмма бик сирәк алар. Әгәр шулай булса, иң зур хак - ата-аналарныкы. Алар остаз да булып тора. Ирләр хатыннарына, әти кеше балаларына - остаз, бигрәк тә дини гыйлемне өйрәтсә.

Хәзер мәчетләрдә дини гыйлемне өйрәнергә мөмкинлек бар. Мин олы, өлкән инде, дип торырга ярамый. Аллаһның рәхмәте булсын, өлкәннәр дә, яшьләр дә йөриләр, хәрефләрне дә танырга өйрәнәләр, аннары балаларыбызга остаз да булырга тиешбез. Ул вакытта безнең алар алдында хакыбыз бигрәк тә зур булыр. Мөгаллимнәр, мөгаллимәләр, укытучылар безне нинди нияттән укыталар: акча өченме, дан өченме, игелек яки бүтән нәрсә өченме? Анысы өчен Аллаһ Тәгалә каршында үзләре җавап бирерләр. Адәм баласына белемне Аллаһ ризалыгы өчен дип бирергә тиеш. Әмма укытучыларның безнең өчен сарыф иткән вакытлары, безнең өчен түккән сәламәтлекләре - бөтенесе дә хәләл. Кайвакыт өйдәге 2-3 балага да түзеп булмый. Без ничек кенә бәяләсәк тә, укытучылар хезмәтләрен, вакытларын, сәламәтлекләрен безнең өчен сарыф итәләр. Безнең өчен борчылалар, безнең өчен сөенәләр, шуның өчен аларның хаклары да безнең өстә бик зур. Без һәрвакыт аларны хәтердә тотарга, зурларга, хәлләрен белергә, үзебезнең көчебездән килгән кадәр ярдәм итәргә тиешбез.

Беренче класска барып керәбез - алар безгә бик якын була, безне укыта. Мәктәпне тәмамлап чыгып китәбез, төрле җирләрдә эшлибез, төрле уңышларга ирешәбез. Әмма остазларыбызны онытып җибәрәбез: әллә булган алар, әллә юк. Әллә алар безнең өчен көч түккән, әллә юк? Бу бит Пәйгамбәребез өйрәткәнчә, Аллаһ Тәгалә кушканча булмый. Остазны онытырга ярамый, белемне инкарь итәргә ярамый. Хәзер безнең җәмгыятебез сәламәт түгел. Белемгә бүген шулхәтле салкын караш, әйтерсең, бөтен дөнья һәрвакыт яман адәмнәр кулында гына булган һәм шулай барачак кебек. Ә белемнең беркайчан да абруе беткәне юк. Белемнең беркайчан да кирәксезгә чыкканы юк. Һәр җәмгыятьтә белем беренче урында булырга тиеш. Моны Аллаһ Тәгалә дә безгә шулай боерды. Белем алырга чыгып киткән баланы тыючы әти-әни, аңа бәддога кылса да, кабул булмый. Әмма бүген без белемгә әллә нинди кирәкмәгән бер нәрсә шикелле итеп карыйбыз. Ә бит дәүләт шартлар тудырган: мәктәпләр якты, җылы, укытучылар бар, балаларны укыталар, мәчетләр төзелгән, мәдрәсәләр эшли, күп мәчетләрдә шулай ук укытучылар, мөгаллимнәр бар. Әмма шуны бәяләп бетермибез. Менә болай битараф яшәсәк, милләт алга китә алмый, аның киләчәге юк. Милләт белемнән суынган икән, аның белемгә игътибары кимегән икән, бу дәүләтнең киләчәге юк. Бу - җәмгыятебезнең чирле икәнен күрсәтә. Әмма бу хәл безнең өстәге бурычыбызны алмый. Мөселман кеше мәктәпләргә, мәдрәсәләргә ярдәм итәргә тиеш. Бүген безнең байларыбыз да бар инде. Акча туплап, бай булып, әллә ничә катлы йортлар салалар, зур-зур өйләр җиткерәләр. Ә мәктәпләребез, йә булмаса, балалар бакчаларыбыз бинаны кечкенә генә төзәтү эшенә дә акча таба алмый интегә.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Сезнең хәерлегез шул кешедер, кем Аллаһ кануннарын, Коръәнне өйрәнеп, шуны кешеләргә җиткерсә». Шушыннан да савaплы эш юк. Бер елны Саба районыннан мәчеткә ай алып кайтып киләбез. Балыклы дигән авылдан. Аны безгә мәрхүм Шәһидулла абыйның кодасы бүләк итеп бирде. Стансадан кайтып киләбез. Яңгырлы, пычрак көз көне. Казаннан Нәҗия апа белән Габделхак абый Каюмовлар стансадан 10-15 чакрым ераклыктагы Ядегәргә дини дәрес бирергә баралар. Менә ул Аллаһ юлында тырышлык. Пенсияләре бар, өйләре җылы. Авылда аларга хезмәт хакы биргән кеше дә юк. Аллаһ ризалыгын өмет итеп йөрүләре. Җомгага берничә адымдагы мәчеткә барырга иренеп утыра кайбер кеше. Ә монда, шундый көнне, Аллаһ ризалыгы өчен, балалар укытырга дип, 70 яшьлек карт белән карчык, поезд белән кайтканнар да, Ядегәр чатына чыгып, машина көтәләр...

Аллаһ юлында тырышу, иҗтиһад күрсәтү менә ничек була. Аллаһ Тәгалә миңа дә менә шуларның шәкерте булырга насыйп итте. Аллаһ Тәгалә мине укыткан укытучыларга да, дингә йөз тотуда дөрес юлны күрсәткән остазларыма да хәерле гомер, сәламәтлек биреп, дин юлында тагын да күбрәк хезмәт итәргә насыйп итсен. Бөтенебезнең дә укытучылары бар бит, искә төшерик. Алар исән икән, хәлләрен белик, мохтаҗлыктамы алар, кайгы-хәсрәтләре бармы - уртаклашыйк, бер җылы сүз әйтсәк, күңелләре үсеп китәр, мәрхүмнәр икән инде, дога кылыйк аларның рухларына.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) бер хәдисендә: «Укытуга алынган кеше әхлак ягыннан үрнәк булырга тиеш», диде. Менә шулай без әле аларга күп таләпләр дә куябыз. Югыйсә, укытучылар да безнең шикелле үк гади кешеләр бит. Тормыш та алып барасылары бар, аларның өстендә бурыч та күп. Шуңа аларның безнең өстә хаклары да бик күп.

Һәркайсыбыз Коръән укып дога кылганда үзенең укытучыларын, мөгаллимнәрен, мөгаллимәләрен, дини вә дөньяви гыйлем бирүчеләрне - барысын да искә алсын иде. Исәннәренә Аллаһ Тәгаләдән хәерле гомер, сәламәтлек сорап, инде мәрхүм булсалар, аларның гөнаһлары ярлыкануны теләп, дога кылса иде. Үзебезгә дә остаз булып, дога кылучылар калдырырлык хәерле гомерләр насыйп булса иде.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ,**
**Татарстанның баш казые.**

## Колак салсаң, үкенмәссең

** Галимнең сүзе гомерең үткәнче,*
*Наданның сүзе ишектән чыкканчы.*
** Галим үләр — сүзе калыр,*
*Йөргән җирендә эзе калыр.*
** Гыйлем күп, гомер аз.*
** Адәм камыт киеп өйрәнми.*
** Өйрәнмичә чабата да үреп булмый.*
** Кайда мәктәп ачылса —*
*анда төрмә бикләнә.*
** Гыйлем булмаганда,*
*бар акыл да юк була.*
** Гыйлемнән башка гамәлең юк,*
*Әйләнергә дә әмәлең юк.*
** Гыйлемсез бер яши,*
*Гыйлемле мең яши.*
** Дөньяны яуларга омтылма,*
*аның гыйлемен яуларга омтыл.*
** Адәм баласы көмеш,*
*Гыйлеме булса — алтын.*
** Җирнең нуры кояш,*
*кешенең нуры гыйлем.*

**Риза ФӘХРЕДДИН**

# Сынауларда сынмас өчен нишләргә?

**Зур максатлар куеп яшәү.** Омтылышлары югары булган кешеләр чыдамлы була, алар тормыш авырлыклары алдында югалып калмый.

**Начар уйларны читкә куу.** Аллаһ рәсүле (с.г. в.): «Берәр начар ырым-шырым сезне хафага салса, туктап калмагыз, эшегезне дәвам итегез һәм Аллаһка тәвәккәлләгез», – диган (әл-Бәйһәкый).

**Урынлы-урынсыз борчылуларны калдырып тору.** Йөрәкне кырган борчулы уйларны күпмедер вакытка калдырып торсаң, соңыннан аларның бөтенләй мәгънәсе югалуы да ихтимал.

**Тормыш авырлыкларына зуррак сынаулар алдыннан чыныгу дип карау.** Күп бөек шәхесләр фәкыйрьлектә үскән, авыр югалтулар кичергән. Авыр тормыш – киләчәктә булачак зур эшләр алдыннан әзерлек ул.

**Үз дәрәҗәңне төшермәү.** Тормышта төрле хәлләр була: эштән куылу, хәләл җефетең белән сүзгә килешү, имтихан тапшыра алмау һәм башкасы. Ләкин шундый хәлләрдән соң, эшем уңмый, мин бернәрсәгә дә ярамыйм, дип, бөтен нәрсәгә кул селтәргә ярамый. Андый очракларда игътибарны мәсьәләне чишү юлларын эзләүгә юнәлтү хәерлерәк. Пәйгамбәр дә (с. г. в.) үз дәрәҗәңне төшермәскә, тормыш авырлыкларын үз кимчелекләреңе белән бәйләмәскә чакырган. Мәсәлән, бер хәдистә шулай диелә: «Берәү дә: "Иманнан яздым", – димәсен. "Хаталандым", – дип әйтегез» (әл-Бохари).

**Җәмгыять эшләренә вакыт бүлү.** Мәсәлән, хәйрия эшләрендә катнашу, мохтаҗларга ярдәм итү, агач үсентеләре утырту, елга буйларын, урманнарны чүп-чардан чистарту һәм башкасы.

**Мәгълүматны «иләк» аша үткәрү.** Җир шарының икенче ягында булган хәбәрләр «һә» дигәнче килеп җитә торган заманда бу аеруча мөһим. Бигрәк тә дәрт-дәрманны сүрелдерә, төшенкелеккә китерә торган һәртөрле мәгълүмат белән мавыгырга кирәкми. Ә менә фән өлкәсендәге, кеше тормышын җиңеләйтә торган төрле яңа ачышлар белән кызыксынып бару дөньяга уңай караш тудыра, киләчәккә өмет уята.

**Мөселман беренче чиратта Аллаһның ярдәменә өмет итә.** Аллаһның, Китабында Үзе вәгъдә иткәнчә, мөэминнәрне һәрвакыт яклап, ризыкландырып, авыр хәлләрдән чыгу юлын күрсәтеп, хәвеф-хәтәрдән аралап торуына ныклы ышану булсын.

**Дилбәр БУЛАТОВА әзерләде.**

# Кыямәт көненең галәмәтләре

Кыямәт көне кайчан буласын Аллаһтан башка беркем белми (фәрештәләр белән пәйгамбәрләр дә белми). Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) бер хәдисендә әйтелә: "Мин сораучыдан күбрәк белмим" (бу - Пәйгамбәребезнең Җәбраил фәрештәнең Кыямәт көне башлануы турындагы соравына биргән җавабы). "Әл-Әхзәб" сүрәсенең 63 нче аятендә Мөхәммәдкә (с.г.в.) дәшеп, Аллаһы Тәгалә әйтә: "Кешеләр синнән Кыямәт көненең кайчан киләчәге турында сорый. Әйт син аларга: бу хакта бары тик Аллаһ кына белә..." ("Әхзәб / Гаскәрләр", 33:63)

Кыямәт көне кайчан буласы билгеле булмаса да, Пәйгамбәребез (с.г.в.) безгә аның галәмәтләрен хәбәр иткән һәм алар галимнәр тарафыннан икегә бүленә: зур галәмәтләр һәм кече галәмәтләр.

Кече галәмәтләр икегә бүленә: булганнары һәм әле булмаганнары.

Булганнары тагын икегә бүленә: кабатланмый торган һәм кабатлана торганнары.

**Инде булган һәм кабатланмаячак галәмәтләр.**

1. Мөхәммәд пәйгамбәрнең килүе. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: "Мин җибәрелдем һәм кыямәт көне миңа бик якын - ике бармак арасы якын булган кебек". Мөхәммәд пәйгамбәрдән соң башка пәйгамбәр булмаячак, ул - Ахырзаман пәйгамбәре.

2. Айның икегә ярылуы. "Камәр" сүрәсенең 1 нче аятендә әйтелә: "Кыямәт көне якынлашты һәм ай икегә бүленде". Әнәс ибне Мәлик исемле сәхабә әйтте: "Мәккә кешеләре Мөхәммәдтән (с.г.в.) могҗиза күрсәтүен сорадылар. Моңа җавап итеп ул Аллаһка дога белән мөрәҗәгать итте һәм күктәге ай икегә ярылды". Габдулла ибне Мәсгут исемле сәхабә риваять итә: "Без пәйгамбәр (с.г.в.) белән Мина тавында утырып торганда, мин айның икегә ярылганын күрдем: бер яртысы тауның бер ягында булды, икенчесе - икенче ягында. Һәм шунда Пәйгамбәребез әйтте: "Айның икегә бүленгәнен карап калыгыз, күрмичә калмагыз".

3. Сүрия өлкәсендә Бусра дигән җирлектә төнлә яктылык җәелү. Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыкларында әлеге хәлне дәлилли торган хәдис бар: "Шундый-шундый җирдә төнлә яктылык җәелер һәм кыямәт көне моннан ерак булмас". Бу вакыйга җомга көнне була (тарихчыларның әйтүләренә караганда, һиҗри буенча 654 елда). Ике көн алдан Мәдинәдә җир тетрәү күзәтелә.

**("Ислам дине нигезләре"ннән.**

Дәвамы бар. Башка галәмәтләр хакында газетаның алдагы саннарында даими биреп барырбыз).

## ӘДӘБИ СҮЗ

### Көз

*Ахшам мәле шәфәкъ алкышында,*
*Сүнеп бара дымык көзге кич...*
*Бик еракта очкан торналарның*
*Тавышлары үзәк өздергеч...*

*Кошлар очар биеклеккә менеп,*
*Карап алам үткән эземә.*
*Бу сагышлы, моңсу көзге кичкә*
*Охшаш кебек бүген үзем дә.*

*Җәйләр үтте,*
*күзләр җитте, диеп,*
*Күпме җаннар эчтән ачына?..*
*Җиргә түгел, тама бәгырьләргә*
*Яңгырдан соң туган тамчылар...*

*Ахшамнарның алсу балкышында*
*Сүнеп бара дымык көзге кич...*
*Сүнсә сүнәр,*
*тик сүнмәсен өмет,*
*Булмасын тик җанда үкенеч...*

***Роберт СӘЛАХИЕВ,***
***Актаныш районы***
***Тат.Суыксу авылы.***

## ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

# Гошер сәдакасы

***Ислам динендә гошер сәдакасы дигән төшенчә бар. Гошер – җирдән җыеп алынган уңышның зәкяте. Мөселман кешесе бакчадан җыеп алган уңышының уннан берен сәдака итеп бирергә тиеш. Казанның Әмәт бистәсе мәчете имам-хатыйбы Равил хәзрәт БИКБАЕВ әйтүенчә, гошер сәдакасын бирергә кирәклеге Коръәндә дә искә алына.***

– «Сыер» сүрәсенең 267нче аятендә: «И мөэминнәр! Кәсеп итеп тапкан малларыгыздан һәм Без сезнең өчен җирдән чыгарган уңышлардан яхшысын Аллаһы күрсәткән урыннарга бирегез!..» – диелә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.с.) тә бер хәдисендә: «Җыеп алынган уңышның яңгыр һәм елга сулары белән үстерелгән өлешеннән – уннан берен, ә хезмәт куеп, ташылып су сибеп үстерелгән өлешеннән егермедән бер өлеше сәдака итеп бирелергә тиеш», – дигән. Моннан чыгып караганда, 100 чиләк бәрәңге алгансыз икән, аның 10 чиләген гошер сәдакасы итеп бирергә тиешсез. Гошер сәдакасы биргәннән генә кеше ач калмый. Киресенчә, Аллаһы Тәгалә сиңа аны икеләтә кайтара. Гошер сәдакасын киләсе елга мул итеп уңыш алу өчен дә бирергә кирәк. Гошер малга бәрәкәт бирә.

Үзем карап, су сибеп үстердем, диючеләр дә бар. Бу ялгыш фикер: бакчада үстергән җимеш, яшелчәләребезнең мул булып үсүендә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте бар. Һәр әйбернең хакыйкый сәбәбе булып Аллаһының рәхмәте тора. Ул насыйп итсә була, итмәсә – юк. Насыйп ризык тешне сындырып керә, дип тә әйтәләр бит бездә. Үз бакчабызда үзебезнең хәләл көчебез белән үстергән булсак та, хезмәт җимешләребезне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән үстерә алганлыгыбызны да онытып җибәрмик, – ди ул.

Гошерне мохтаҗ кешеләргә, ятимнәргә, ялгыз кешеләргә, мәдрәсә шәкертләренә бирү дөрес санала. Аны бирүнең төгәл вакыты юк. Гадәттә, уңышны җыеп алгач бирәләр. Сакларга урыны булмаганнар шулай итә. Соңрак та ярый.

***– Балдан да гошер бирергәме?***

– Әбү Хәнифә мәзһәбендә балның да гошере бар. Аның да уннан бер өлеше гошер була. 100 килограмм бал алсаң, шуның 10 килограммын сәдака итеп бирергә кирәк.

***– Гошер сәдакасын бирмәсәң, гөнаһлы буласыңмы?***

– Әйткәнемчә, ул – зәкятнең бер төре. Мөмкинлегең була торып бирмәү – гөнаһ. «Ибраһим» сүрәсенең 7нче аятендә: «Мин биргән нигъмәтләргә шөкерана кылсагыз, арттырып бирермен. Әгәр биргән нигъмәтләремә шөкерана кылмасагыз, газабым каты булыр», – дигән. Бу урында мин фермерлар, колхоз, инвесторлар, күмәк хуҗалыкларны да гошер бирергә чакырыр идем. Алар бодаен да, кукуруз, рапс, көнбагышын да утырта. Гошер ул бәрәңге генә дигән сүз түгел. Әбү Хәнифә мәзһәбендә җирдә үскән бөтен әйбердән гошер чыгару каралган, фәкать утын белән камыш кебек нәрсәләрдән генә гошер чыгарылмый.

***– Тиешле гошерне бирмәсәң, Аллаһы Тәгалә яңгырын вакытында бирмәс, ди. Бу чынлап та шулаймы?***

– Андый хәдис дөрестән дә бар. Яуган яңгырда хайваннар өлеше генә булыр, ягъни хайваннар булмаса, аны да яудырмас иде...

**Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА**
**("Шәһри Казан").**

## РУХИ ХӘЗИНӘ

# Без – Мөхәммәд өммәте

Әссәләмүгаләйкүм, кадерле кардәшләребез, сезгә Аллаһның рәхмәте һәм бәрәкәте булсын! 6нчы гасырда, ягъни сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм туган, үскән заманнарда, кешелек әхлак, иман ягыннан нинди чиккә килеп җиткән, шул хакта бераз искә төшереп үтик әле. Ул чорда дөньядагы бар халыклар күп иләһләргә, үзләре ясаган потларга табынып яшәгән. Дөньяда мәҗүсилек хөкем сөргән, бер Аллаһка ышанучылар аз калган. Һәм алар арасында яһүдиләр, христианнар коткаручы яңа пәйгамбәр килүен зарыгып көтеп яшәгәннәр. Мәрхәмәтсезлек, әхлаксызлык киң җәелгән. Күп кешеләр исерткеч эчкәннәр, алдау һәм юлбасарлык юлы белән байлык туплаганнар. Кешеләрнең кадере булмаган. Колларны интектергәннәр, хайван кебек яшәткәннәр. Хатын-кызларның да кыймәте булмаган. Гарәпләр арасында хәтта шундый гадәт киң таралган: кыз бала туса, ата кеше, намус эшенә санап, баласын тере килеш күмеп куйган. Кабиләләр арасындагы сугышлар юк кына сәбәпләрдән башланып, дистәләгән еллар дәвам иткән, кайчак сәбәбе онытылса да, сугыш тукталмаган.

Сөекле Пәйгамбәребез галәйһиссәләм бар кешелек шушындый кызганыч түбәнлеккә тәгәрәгән заманда туган һәм үскән. Саф җанлы, иманлы булганга, мондый хәлләргә борчылып яшәгән ул. 40 яше җитәрәк, нидер көткән сыман, булачак Рәсүлебез Хира тавының Нур мәгарәсенә менеп уйлана торган булган, аулактагы вакытын бер Аллаһка гыйбадәт кылып, галәм һәм дөньяны бар кылучы куәт турында фикерләп үткәргән. Һәм Рамазан аеның Кадер кичендә аңа мәгарәдә Раббыбыздан иң тәүге аять иңгән. Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә Коръән аятьләре Җәбраил гәләйһиссәләм аша иңдерелгән. Ул Аллаһы Тәгалә белән пәйгамбәрләр арасында арадашчы олы фәрештә.

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм Нур мәгарәсендә булганда, аның янына Җәбраил фәрештә килеп, "Икра!" (Укы!) дип боерган. Ләкин Рәсүлебез укый да, яза да белмәгән. Шуңа: "Мин укый белмим", - дигән. Җәбрәил фәрештә аны кысып, тагын: "Укы!" – дип кабатлаган. Пәйгамбәребез (галәйһиссәләм) яңадан: "Укый белмим", - дип әйткән. Шулчак Җәбраил фәрештә аны өченче тапкыр нык кочаклап кыскан да җибәргән һәм: "Һәрнәрсәне Бар Итүче Раббың исеме белән укы!" - дигән. Шулай итеп, кешелеккә "Галәкъ" сүрәсенең беренче биш аяте җибәрелгән. Тәүге аятьләрне кыскача мәгънәләре белән укып та китик.

"Икра, бисмиРаббикәлләзи халәкъа - Һәрнәрсәне Бар Итүче Раббың исеме белән укы!

Халәкал – иңсәнә мин гәләкъа - Ул кешене оешкан каннан бар итте.

Икра, вә Раббүкәл-әкрам - Укы, Синең Раббың иң юмарт.

Әлләзи гәлләмә бил-каләм - Ул кешене каләм белән өйрәтте.

Гәлләмәл-иңсәәнә мәәләм йәгъләм" – моңа кадәр белмәгәнен өйрәтте!"

Пәйгамбәребез галәйһиссәләм мәгарәдә булган хәлдән калтыранып, нык дулкынланып өенә йөгергән. Таудан төшкәндә, Җәбраил галәйһиссәләм аңа: "Әй, Мөхәммәд! Син – Аллаһ рәсүле, ә мин – Җәбраил", - дигән. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм хатыны Хәдичә янына кайтып, үзен капларга кушкан. Хәдичә (Аллаһ аннан риза булсын) аны каплаган, пәйгамбәребез (с.г.в.), йөрәгендә куркуы беткәнче, шулай капланып утырган. Шуннан соң бар нәрсәне Хәдичә анабызга сөйләп биргән. Хатыны аны юатып: "Курыкма, Аллаһ сиңа хәерлесен бирер. Син иң күркәм холыклысың. Кардәшләрең белән бәйләнештә торасың, мескеннәргә ярдәм итәсең, кешеләргә кунакчыллык күрсәтәсең, аларга язмыш сынауларын күтәрергә булышасың. Аллаһ Сине хурлыкка калдырмас", - дигән.

Хәдичә анабыз Мөхәммәд галәйһиссәләмнең рәсүл булуына барлык кешеләр арасыннан иң беренче булып иман китергән. Мәгарәдәге вакыйгадан соң Хәдичә (Аллаһ аннан риза булсын) Мөхәммәд галәйһиссәләмне христиан динендә булган үзенең туганнан туганы Вәрәка ибн Нәүфәл янына алып бара. Бу вакытка ул инде сукырайган карт булса да, изге китапларны белгән була. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм аңа күргәннәрен сөйләп бирә. Һәм Вәрәка болай ди: "Сиңа килгән фәрештә – ул Җәбраил фәрештә, Аллаһ Мусага да аны җибәргән! Мин яшь булсам иде, синең халкың сине куа башлаган көннәргә кадәр яшәсәм иде, сине яклар идем, булдыра алганча булышыр идем", – ди. Шунда РәсүлАллаһ аптырап: "Мине куачаклар мени?" – дип сорый. Вәрака аңа: "Бер Аллаһны аңлатучы пәйгамбәрләргә һәрчак каршы торганнар, нык бул",– дип әйтә.

Авыр сынаулар үтеп, Пәйгамбәребез галәйһиссәләм 23 ел дәвамында надан, әхлаксыз халыкларны Аллаһ сүзе белән тәрбияләгән, аларны күркәм әдәпле, укымышлы иткән. Алга таба да Мөхәммәд галәйһиссәләм турында сөйләшүебезне дәвам итәрбез, ин шә Аллаһ.

**Язманы "Хәзинә" клубы мөгаллимәсе**
**Әлфия МӨДӘРИСОВА әзерләде.**

# Җавап бирәсе бар

Аллаһ байлыкны сынау өчен бирә. Беркөнне ул байлык китеп, син ярлы да булырга мөмкинсең. Бүген синнән дә баерак кеше юктыр шәһәрдә , ләкин бер елдан соң синнән дә ярлырак кеше калмас. Сандыгыңны байлык белән тутырганда, ахирәт сандыгын да тутырырга онытма. Аллаһ ул сандыкны тутырырга тыймады, ләкин ул сандык янында тагын бер сандык торсын. Ахирәт сандыгы да тулып торсын. Байлыгың бар икән, аны файдага куллан. Аны мохтаҗларга, кардәшләргә куллан, чөнки ул синең кулыңнан китәргә мөмкин. Без күрәбез: кешеләр хәтта вертолетларда йөриләр, аннары фәкыйрь булып, вафат булалар. Хәтта кайчандыр байлыгына карап торучылар аны күмәргә дә килмиләр. Күпме ата байлык калдыра да балаларга, шул балалар байлык өчен талашып, судлашып бетәләр, атаны рәнҗетеп, юк итәләр. Кесәңдә нәрсәдер бар икән, файдалан, чөнки ул кесәңнән чыгып киткәч, аны файдаланып булмый. Пәйгамбәребезнең хәдисен дәвам итәбез: "Малы турында соралыр". Каян алды ул аны, һәм ул аны кая сарыф итте: хәләлгәме, хәрамгамы. Кеше һәрбер малы өчен кыямәт көнне җавап бирәчәк.

Вакытыңны куллан изгелектә, хәтта тормышыңда шундый хәлләр килеп чыгып, сине изгелек кылырга да вакыт калдырмаячак. Күпме яшьләр иртән торып, нәрсә эшләргә белмичә йөриләр. "Монда барып баш төзәтимме, монда барып хәмер эчимме, кәрт сугыйммы икән?" Менә шулай алар буш вакытларын кәеф-сафа, уен-көлке белән үткәрәләр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) : "Ике төрле байлык бар, берсе – сәламәтлек – аның кадерен югалткач кына беләсең, икенчесе – вакыт". Бер галим анекдотлар сөйләшеп, уен-көлке белән шөгыльләнеп утыручыларны күрә. Аларга карап, ул болай ди: "Вакыт дигән әйберне сатып алып булса иде. Бу кешеләрнең вакытларын үземә сатып алыр идем". Чөнки мөэминнең вакыты юк бу дөньяда, чөнки ул һәрбер вакытын файдага үткәрә. Аның вакыты гайбәт сөйләргә, яманлык кылырга юк. Аның эше күп: гыйбадәтен кыласы бар, гыйлемен аласы бар, хәләл кәсеп итәсе бар, кешеләрне исламга чакырасы бар. Шуңа күрә, эше булмаган кешеләр генә интегәләр. Ләкин кыямәт көнендә кешенең вакыты турында да соралыр.

**Йосыф хәзрәт ДӘҮЛӘТШИН.**

# Дөнья да шул коега охшаш...

Бер авыл кешесенең ишәге иске, корыган, тирән коега төшкән. Хуҗасы исә, ишәгенең ярсып кычкырганын ишетеп, кое янына йөгереп килә, өстән аска таба карый да, башын кашып, үз-үзенә: "Бу карт ишәкне әлеге тирән коедан чыгаруның бер хикмәтен күрмим», - дип, шушында кое белән бергә күмеп куярга карар кыла һәм ярдәмгә авыл халкын чакыра. Ниһаять, халык җыелып, коены күмә башлагач, ишәк, нәрсә эшләргә җыенганнарын аңлап, бик каты кычкыра, ләкин күпмедер вакыт үткәннән соң аның тавышы чыкмый башлый. Ни булды икән дип карасалар, гаҗәп, шаккатыргыч бер нәрсә күрәләр. Ул да булса, ишәк, өстенә ташлаган туфракны кагып төшерә икән һәм аяк астына төшкән җиргә басып, күтәрелгәннән күтәрелә бара. Коеның өстенә кадәр күтәрелгәч, кул озынлыгында калгач, халык аны коедан сөйрәп чыгара. Шулай итеп ишәк үлемнән котыла.

Хөрмәтле дустым, безнең өчен дөнья - ишәк егылып төшкән коега охшаш. Ишәкне күмәргә дип ыргытылган җир дә кешенең башына килгән сынауларга тиң. Шуны аңлаган кеше, дөньяда килгән сынауларга нык булса, бирешмәсә - уңышка ирешер, аның дөнья тормышы сөенеч белән нокталаныр.

**(Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН. "Бәхетлеләрнең серләре")**

# ЯРЫЙ ӘЛЕ КАНАТЫ ЮК...

*Берничә кеше тормыш авырлыкларыннан зарланып Хуҗа Насреддингә шикаять белдергәч, Хуҗа әфәнде аларга нәсыйхәт кылырга теләп, болай диде:*

*- Әй җәмәгать! "Ярый әле сыерларның канатлары юк!" – дип Аллаһы Тәгаләгә шөкер итегез! Юкса, йорт түбәләре сезнең өстегезгә ишелеп кенә торыр иде!.*

**Кыскача нәсыйхәт:** *Бу дөньяда барысы да Адәм балаларына җайлы, уңайлы булсын дип зур хикмәт белән бар ителгән. Булганның кадерен белеп, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итеп, ниятләнгән эшләребезнең уңышлы башкарылуын сорап, зарланмыйча гына сабыр булып яшик...*

## *Балалар өчен*



# Файдалы бул!

Файдалы бул кешегә!
Торса да файдаң бер тиенгә.
Тамчыдан күл җыела,
Гамәл китабыңа язылы!
Файдалы бул кешегә!
Туганыңа, күршеңә.
Була әҗер-савап та
Сукмактан ташны алсаң да.
Файдалы бул кешегә!
Кошларга, җәнлекләргә.
Кош оясына җим сал,
Пәйгамбәрдән үрнәк ал!
Файдалы бул кешегә!
Файдаң тисен галәмгә.
Елмаюдан син башла,
Зур гамәл белән дәвамла!
Файдалы бул кешегә!
Үрнәк бар сөннәт, хәдистә.
Үрнәк безгә Пәйгамбәр,
Кыл син яхшы гамәлләр!

**Алинә ХӘБИБУЛЛИНА, "Асыл зат" төркеме җитәкчесе.**

## Саулыгым – байлыгым

# Кызыл миләш



Кызыл миләш дәвалау үзлекләренә ия. Аның согын халык медицинасында атеросклерозны һәм гипертоник авыруларны дәвалау өчен файдаланалар. Миләш төнәтмәсе дизентерияне дәвалау өчен дә кулланыла. Ашказаны, эчәк авырулары вакытында аннан төнәтмә ясап эчәргә киңәш ителә. Миләш согы бөердән ташларны чыгару өчен дә файдаланыла. Моның өчен 400г миләшне изәләр, аңа 2 литр кайнаган су һәм бераз шикәр комы салалар, дүрт сәгатьтән соң болгатып сөзәләр һәм эчәләр. Эч катканда берничә атна буена көнгә өч тапкыр 70-100 грамм шундый сок эчәргә киңәш ителә. Ул бөердән ташларны чыгарырга да булыша. Табиблар диабет белән авырганнарга, бавыры авырткannarга миләш ашарга куша. Азканлылык булганда, ике аш кашыгы кызыл миләш җимешен ике стакан кайнар суга салалар, бер сәгать төнәткәч, сөзәләр. Шуны көн буена өч-дүрт тапкыр аз-азлап эчәләр. Үт куыгы ялкынсынган (холецистит) кешеләр дә миләш согыннан файда күрәләр. Кан басымын нормада тоту өчен дә кулланыла. Кызыл миләшне изеп, шикәр комы һәм кайнар су белән болгатып, йоклар алдыннан эчү дә файдалы.

***(Фотолар интернеттан алынды)***

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**
**Баш мөхәррир**
**Муллагалиева А. Г.**
**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45
* * *
**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән хатларда авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
islamgazeta@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы: 1500**
**Индексы 54149**
* * *

Хөрмәтле укучыбыз!
Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

**Нәшир, типография һәм редакция адресы:**
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**
**Басарга кул куелды:**
**график буенча 26 сентябрь 16 сәг.**
**фактта 26 сентябрь 16 сәг.**
**Бәясе ирекле**